**Республика Татарстан**
**Менделеевский муниципальный район Совет**
**Татарско-Челнинского сельского поселения**

**Татарстан Республикасы**
**Менделевск муниципаль районы**
**Татар -Чаллысы авыл җирлеге Советы**

---

# РЕШЕНИЕ

2020 елның 29 октябреннән N8

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлегендә
бюджет процессы турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2020 елның 24 гыйнварындагы 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 10 статьясындагы 2 абзацын үз көчен югалткан дип санарга.

1.2. Нигезләмәнең 39 статьясындагы 2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә һәм бюджет турындагы карар проектын керткәннән соң кабул ителгән үзгәрешләр Җирлек Советына карауга китерә торган Җирлек Советы Карарлары Чираттагы финанс елында, агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә үзгәрешләр керткәндә исәпкә алына.»

1.3. Нигезләмәнең 51 статьясындагы 1 пунктының 2 абзацында "яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әлеге орган исеменнән эш итәргә вәкаләтле башка зат" сүзләрен өстәргә».

2. Әлеге карарны Татар Чаллысы авылына махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Татар Чаллысы авыл җирлеге" бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Татар Чаллысы авыл җирлеге
Советы Рәисе Т.П.Кузнецова